РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс +7(84396) 2-59-00, email: cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru

11.03.2021 №34

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Советы
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль
районы Советының 2020 елның 26 июнендәге
«Аренда түләүләрен түләүне кичектереп тору
өлешендә кече һәм урта эшмәкәрлек
субъектларына ярдәм күрсәтү чаралары турында»
279 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 19 мартындагы «Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм чаралары турында» 670-р номерлы күрсәтмәсенә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 22 апрелендәге 820-р номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 25 маендагы 1015-р номерлы, 2020 елның 14 августындагы 1536-р номерлы, 2020 елның 28 декабрендәге 2963-р номерлы боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән) таянып, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2020 елның 26 июнендәге 279 номерлы «Аренда түләүләрен кичектереп тору өлешендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү чаралары турында» карарына (Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2020 елның 28 августындагы 293 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 1 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә: «1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы милкендә булган, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы казнасын тәшкил иткән муниципаль мөлкәтне (алга таба - муниципаль милек) (шул исәптән җир

кишәрлекләрен) арендалау шарнамәләре буенча, арендалаучылар мөрәҗәгать иткән көннән җиде көн эчендә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

а) түбәндәге шартларда кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектлары белән 2020 елның 1 апреленә кадәр төзелгән аренда шартнамәләренә аренда түләүләрен түләүне кичектереп торуны күздә тоткан өстәмә килешүләр төзү:

кичектерү 2020 елның 1 апреленнән 2021 елның 1 гыйнварына кадәр бирелә, ә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 22 апрелендәге 821-р күрсәтмәсе нигезендә аренда түләүләрен түләүдән азат ителгән арендаторлар өчен - 2020 елның 1 июленнән алып 2021 елның 1 гыйнварына кадәр;

аренда түләве буенча бурыч арендага алучылар тарафыннан тәкъдим ителгән вакытка 2021 елның 1 гыйнварыннан иртәрәк түгел, әмма 2023 елның 1 гыйнварыннан да соңга калмыйча, этаплап, айга бер тапкырдан да артмыйча, аренда шартнамәсе буенча айлык аренда түләвенең яртысы күләменнән артмаган күләмдә тигез түләүләр белән түләнергә тиеш;

кичектерүгә бәйле рәвештә, арендатор тарафыннан аренда түләвен кертү тәртибен һәм срокларын сакламау (шул исәптән мондый чаралар аренда килешүендә каралган очракларда) белән бәйле рәвештә, чит акчалардан файдаланган өчен штрафлар, процентлар яки башка җаваплылык чаралары кулланылмый;

кичектереп тору белән бәйле рәвештә арендатор тарафыннан түләнергә тиешле өстәмә түләүләрне билгеләү рөхсәт ителми;

б) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 23 июнендәге «Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар реестры турында» 906 номерлы карары нигезендә социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар реестрына һәм (яки) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 11 июнендәге «Яңа коронавирус йогышы таралу нәтиҗәсендә хәл начараю шартларында аеруча зыян күргән коммерцияле булмаган оешмалар реестры турында» 847 номерлы карары нигезендә яңа коронавирус йогышы таралу нәтиҗәсендә хәл начараю шартларында иң күп зыян күргән коммерцияле булмаган оешмалар реестрына кертелгән оешмалар белән (алга таба-социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар), Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яки гадәттән тыш хәл режимын кертү турында 2020 елда карар кабул ителгәнче төзелгән аренда килешүләренә аренда түләүләрен түләүгә кичектереп тору бирүе каралган өстәмә килешүләр төзү түбәндәге шартларда:

кичектерү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 22 апрелендәге 821-р күрсәтмәсе белән каралган аренда түләвеннән азат итүне исәпкә алып, Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимы гамәлдә булган бөтен чорга бирелә;

кичектерү Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Яңа коронавирус йогышы таралу нәтиҗәсендә хәл начараю шартларында иң күп зыян күргән Россия икътисады тармаклары исемлеген раслау турында» 2020 елның 3 апрелендәге 434 номерлы карары белән расланган яңа коронавирус инфекциясе таралу нәтиҗәсендә килеп туган хәлнең начараюы шартларында иң күп зыян күргән Россия икътисады тармаклары исемлеге (алга таба - исемлек) буенча бер яки

берничә тармакта социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешма эшчәнлегенә, шулай ук Юридик затларның бердәм дәүләт реестрында булган төп яки өстәмә икътисадый эшчәнлек төрләре турында 2020 елның 1 апреленә булган мәгълүматка бәйсез рәвештә бирелә;

аренда түләве буенча бурыч арендага алучылар тарафыннан тәкъдим ителгән вакытка 2021 елның 1 гыйнварыннан иртәрәк түгел, әмма 2023 елның 1 гыйнварыннан да соңга калмыйча, этаплап, айга бер тапкырдан да артмыйча, аренда шартнамәсе буенча айлык аренда түләвенең яртысы күләменнән артмаган күләмдә тигез түләүләр белән түләнергә тиеш;

кичектерүгә бәйле рәвештә, арендатор тарафыннан аренда түләвен кертү тәртибен һәм срокларын сакламау (шул исәптән мондый чаралар аренда килешүендә каралган очракларда) белән бәйле рәвештә, чит акчалардан файдаланган өчен штрафлар, процентлар яки башка җаваплылык чаралары кулланылмый;

кичектереп тору белән бәйле рәвештә арендатор тарафыннан түләнергә тиешле өстәмә түләүләрне билгеләү рөхсәт ителми;

в) Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында арендаторлар - кече һәм урта эшкуарлык субъектлары һәм социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар өчен әлеге пунктның «а» һәм «б» пунктчалары нигезендә өстәмә килешүләр төзү мөмкинлеге турындагы мәгълүматны әлеге карар үз көченә кергән көннән җиде эш көне эчендә урнаштыру.

1.2. 2 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә: «2. Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яки гадәттән тыш хәл режимы кертелгән көнгә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының муниципаль казнасын тәшкил иткән муниципаль мөлкәтне (шул исәптән җир кишәрлекләрен) арендалау шартнамәләре буенча узган чор өчен аренда түләүләрен түләү буенча үтәлмәгән бурычлары булмаган, әлеге карарның 1 пунктындагы «а» и «б» пунктчаларында күрсәтелгән арендаторларга аренда түләүләрен түләүгә кичектерү бирелә дип билгеләргә. Аренда килешүен вакытыннан алда өзгәндә аренда түләве буенча бурыч бер үк вакытта түләнә».

1.3. 2* пунктны 3 пункт дип санарга һәм яңа редакциядә бәян итәргә: «3. 2020 елның 1 апреленә кадәр төзелгән, Исемлек буенча бер яки берничә тармакта эшчәнлек алып баручы кече һәм урта эшкуарлык субъектлары һәм социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар арендаторлар булып торучы муниципаль милекне арендалау шартнамәләре буенча, 2020 елда Татарстан Республикасы территориясендә гадәттән тыш хәл яки югары әзерлек режимын кертү турында карар кабул ителгәнче төзелгән шартнамәләр буенча, Исемлек буенча бер яки берничә тармакта эшчәнлек алып баруга, шулай ук Юридик затларның бердәм дәүләт реестрында 2020 елның 1 апреленә булган икътисадый эшчәнлекнең төп яки өстәмә төрләре турында мәгълүматка бәйсез рәвештә башкарма хакимият органнарына, шулай ук алар карамагында булган муниципаль предприятиеләргә һәм муниципаль учреждениеләргә аренда түләвен түләүне кичектереп торуны түбәндәге шартларда бирергә:

кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына - 2020 елның 1 апреленнән алып 21 елның 1 гыйнварына кадәр;

социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга - Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яки гадәттән тыш хәл режимы гамәлдә булган бөтен чорга;

аренда түләве буенча бурыч 2021 елның 1 гыйнварыннан да иртәрәк түгел һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан да соңга калмыйча, этаплап, айга бер тапкырдан да артмыйча, аренда шартнамәсе буенча айлык аренда түләвенең яртысы күләменнән артмаган күләмдә тигез түләүләр белән түләнергә тиеш;

кичектерүгә бәйле рәвештә, арендатор тарафыннан аренда түләвен кертү тәртибен һәм срокларын сакламау (шул исәптән мондый чаралар аренда килешүендә каралган очракларда) белән бәйле рәвештә, чит акчалардан файдаланган өчен штрафлар, процентлар яки башка җаваплылык чаралары кулланылмый;

кичектерү бирелүгә бәйле рәвештә арендатор тарафыннан түләнергә тиешле өстәмә түләүләр билгеләү рөхсәт ителми;

арендаторның тиешле мөрәҗәгате кергән көннән соң җиде эш көне эчендә кичектереп торуны күздә тоткан аренда шартнамәләренә өстәмә килешүләр төзелергә тиеш;

кичектерү Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яки гадәттән тыш хәл режимы кертелгән көнгә дәүләт мөлкәтен арендалау килешмәләре буенча узган чор өчен аренда түләүләрен түләү буенча үтәлмәгән бурычлары булмаган арендаторларга бирелә».

1.4. Карарга түбәндәге эчтәлекле 4 пунктны өстәргә: «4. Аренда түләвен түләүне кичектереп торуны бирү шартлары мондый килешү төзү датасына бәйсез рәвештә кичектерү турында өстәмә килешүләргә карата кулланыла дип билгеләргә».

1.5. Карарның 3 пунктын «5» пункты дип санарга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

Муниципаль район башлыгы урынбасары,
Совет рәисе урынбасары Г.М. Җамалетдинов